КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 19 апрель г.Казань № 258

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары тарафыннан суд эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле биналар (урыннар) бирү тәртибе турында” 2013 ел, 5 сентябрь, 634 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары тарафыннан суд эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле биналар (урыннар) бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары тарафыннан суд эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле биналар (урыннар) бирү тәртибе турында” 2013 ел, 5 сентябрь, 634 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 27 сентябрь, 868 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары тарафыннан суд эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле биналар (урыннар) бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участокларын урнаштыру өчен биналар төзелеше бер суд участогына кимендә 205 кв.метрлык хезмәт мәйданы күләмендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участокларын элек төзелгән биналарда (бүлмәләрдә) урнаштырганда бер суд участогына хезмәт мәйданы шушы Тәртипкә кушымтада күрсәтелгән Татарстан Республикасы җәмәгать судьясының бер суд участогында суд эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле хезмәт урыннары булуны тәэмин иткәндә әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгәннән кимрәк булырга мөмкин.»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясының бер суд участогында суд хөкемен гамәлгә ашыру өчен кирәкле хезмәт урыннары исемлеге әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә билгеләнә.»;

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары тарафыннан гадел хөкемне гамәлгә ашыру өчен кирәкле биналар (бүлмәләр) бирү турында тәкъдимнәр кергән очракта, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы күрсәтелгән тәкъдимнәр кергән көннән 14 көн эчендә биналарны (бүлмәләрне) карый.

Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участокларын тәкъдим ителгән биналарда (бүлмәләрдә) урнаштыру мөмкин булмаган очракта, шул исәптән Татарстан Республикасы җәмәгать судьясының әлеге Тәртипкә кушымтада күрсәтелгән бер суд участогында суд эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле хезмәт бүлмәләре булуын тәэмин итү мөмкинлеге булмауга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы карау тәмамланган көннән алып өч көн эчендә биналар (бүлмәләр) кабул итүдән баш тарту турындагы тәкъдимне юллаган органга язма рәвештә хәбәр итә.»;

10 пунктта «соңыннан 5 көн эчендә» сүзләрен «көннән соң 14 көн эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Тәртипкә кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
җәмәгать судьялары тарафыннан
суд эшчәнлеген гамәлгә ашыру
өчен кирәкле биналар (урыннар)
бирү тәртибенә кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының 2021
ел, 19 апрель, 258 нче карары
редакциясендә)

Татарстан Республикасы җәмәгать судьясының бер суд участогында гадел хөкем башкару өчен кирәкле хезмәт бүлмәләре исемлеге

| Т/с | Бүлмә |
|---|---|
| 1. | Җәмәгать судьясы кабинеты |
| 2. | Җәмәгать судьясының киңәшмә бүлмәсе (хезмәт мәйданнары булганда) |
| 3. | Суд утырышы залы |
| 4. | Җәмәгать судьясы аппараты хезмәткәрләрен урнаштыру өчен кабинетлар |
| 5. | Суд участоклары администраторының кабинеты (хезмәт мәйданнары булганда) |
| 6. | Судлар эшчәнлегенең билгеләнгән тәртибен тәэмин итү буенча суд приставы кабинеты |
| 7. | Азык кабул итү бүлмәсе (хезмәт мәйданнары булганда) |
| 8. | Архив өчен бүлмә |
| 9. | Склад бүлмәсе (хезмәт мәйданнары булганда) |
| 10. | Сервер бүлмәсе (хезмәт мәйданнары булганда) |
| 11. | Хезмәт санитар төене |
| 12. | Хәрәкәтләнү мөмкинлекләре чикләнгән халык төркемнәренә һәм килүчеләр өчен санитар төене (аерым яки берләштерелгән) |
| 13. | Гаепләнүчеләр өчен санитар төене булган конвой бүлмәсе (хезмәт мәйданнары булганда) |